**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

«04» апрель, 2023 ел

№ 305

Торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә социаль ярдәм чараларын күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2005 елның 20 апрелендәге 192 номерлы карары, торак һәм яшәү өчен түләү буенча «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2005 елның 07 июнендәге 251 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар чыгарды:

1. Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче муниципаль учреждениеләр белгечләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтүне түбәндәге категориядәге гражданнарга билгеләргә:

- мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсе хезмәткәрләренә торакка түләү, җылылык, яктырту чыгымнарының 100 проценты күләмендә торак, җылылык өчен түләү чыгымнарының, Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән торак мәйданының социаль нормасы чикләрендә яктыртуның һәм коммуналь хезмәтләрне куллану нормативларының 100 проценты күләмендә. Күрсәтелгән социаль ярдәм чарасы авыл җирендә урнашкан мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләрендә кимендә 10 ел эшләгән һәм шунда яшәгән, шулай ук Россия Федерациясе системасы бюджетларына салымнар,

җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлары булмаган хезмәткәрләрдә саклана.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының финанс-бюджет палатасына бюджет формалаштырганда район бюджетының өстәмә чыгымнарын каплау чыганакларын билгеләргә.

3. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында» 2023 елның 26 апрелендәге 292 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында http://pestreci.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру (халыкка җиткерү) юлы белән бастырып чыгарырга:

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль район
Башкарма комитеты җитәкчесе В.И. Никитин